ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.03.2018 г.Мензелинск № 225

2003 елның 6 октябрендәге «РФ»да җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131 Федераль законы, 2006 елның 6 мартындагы “Терроризмга каршы тору турында”гы №35 Федераль законы, РФ Бюджет кодексының 179 маддә, 2 өлеше, Минзәлә муниципаль районы Уставын кулланып,

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1. 29.12.2017 елдагы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының №1550 карары белән расланган “2018-2020елларга Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау буенча район максатчан программасы” муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетын программага заказ бирүче итеп билгеләргә.

б) “Программа координаторы - Минзәлә муниципаль районында Террорга каршы комиссия” юлын өстәргә.

в) “Республика территориясендә яшәүче халыклар язучыларының китаплары буенча “Татарстан – безнең дус гаиләбез” кечкенә хикәяләр, шигырьләр, әкиятләр еллык республика конкурсларында катнашу” 3.4 пунктын төшереп калдырырга;

г) 3.9 пунктының башкаручылар юлына мәгариф бүлеге, мәдәният бүлеге, яшьләр бүлеген өстәргә;

д) 3.11 пунктының башкаручылар юлына мәгариф бүлеге, мәдәният бүлеге, яшьләр бүлеген өстәргә.

2. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы: В.Р.Гыйләҗетдинов.